**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының**
**Иске Матвеевка авыл җирлеге составына керүче**
**Иске Александровка торак пунктында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**27.11.2023 ел** **№ 3**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 27.11.2023 елда узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Александровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,түбәндәгеләрдән тыш:көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I һәм 2 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар,Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, аларның гаилә әгъзалары, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Иске Александровка торак пунктында Гагарин урамындагы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу,китертү, салу килешү буенча эш өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 45 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 28 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен җыенда катнашкан 24 кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:
1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Александровка торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Александровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,түбәндәгеләрдән тыш:көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I һәм 2 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар,Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр,мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Иске Александровка торак пунктында Гагарин урамындагы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу,китертү, салу килешү буенча эш өчен түләү, ).

2. Иске Матвеевка авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен халыкка игълан итү http://menzelinsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo tatarstan урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ М.Н. Галимҗанов
(имза)

Иске Матвеевка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ______________ М.Н.Галимҗанов
(имза)